# Коръән елы игълан ителү уңаеннан

### Коръән ятлыйм дисәң...

Мәдрәсәгә йөрүче һәр кешенең, гомүмән алганда һәр мәселманның иң изге хыялы әлбәттә Коръән ятлау буладыр. Коръән укуның, аны яттан белүнең фазыйләтләре , саваплары санап бетергесез.Танылган гарәп Коръән хафизы(Коръәнне яттан белүче) Мишари Рашид безгә нинди киңәшләр бирә соң?

1. Аллаһ ризалыгы өчен ятлау.

   Кайбер вакытта кардәшләребезнең гамәлләрен күргәзмә өчен башкарганнарын күрәбез. Динебездә исә ихласлык, эшне Аллаһ ризалыгы өчен башкару беренче урында тора. Шул исәптән имам Мөслим һәм Бухари да үзләренең хәдис җыентыкларын ният хакындагы хәдисләр белән башлаганнар.

2. Максат билгеләү.

   Мәсәлән: “Мин тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнгәч бер җүз Коръән ятлыйячакмын һәм бар тырышлыгымны куячакмын.

3. Һәрдаим Корән ятлауга вакыт билгеләү һәм әлеге графиктан тайпылмау.

   “Иң хәерле эш-дәвамлы эш” дигән гыйбәрәне истән чыгармау мөһим.

4. Шөгелләнергә иң кулай булган вакытны һәм урынны сайлау.

   Әгәр дә сезгә өйдә укырга балалар комачаулый икән, димәк сезгә мәчеткә барып өйрәнергә кулайрак булыр.

5. Өйрәнер өчен билгеле бер Коръән сайлау.

Авторның бу хакта әйтүе очраклы түгел, чөнки кешенең күз хәтер сәлате бар, димәк Коръәннең билгеле бер төр шрифтына күнеккәч, аны алыштыру киңәш ителми.

6. Авырлыклардан курыкмау.

Гадәттә башлап җибәрүчеләр начар хәтер яисә хәрефләрнең авыр әйтелеше белән бәйле булган мәсъәләләргә юлыгалар. Әлбәттә, бу вакытлыча күренеш. Ләкин, кайбер мөселманнар шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, дәресләрен ташлыйлар. Алардан төрле сәбәпләр ишетергә туры килә: ”Мин мәктәптә начар укыдым, миннән булмас инде” яисә “мин картайдым, зиһенем дә юк ”.

7. Коръәнне үзлектән үзләштерәсез икән, дөреслеген белүче кешедән тикшертегез.

8. Коръәнне укыган вакытта, кычкырып укырга тырышыгыз. Башта бер аятьне өйрәнегез, аннан икенчесен ятлагыз, аннан соң икесен бергә кушыгыз. Шул рәвешле дәвам итегез. Тәһәратле булыгыз. Укыган вакытта төз утырыгыз, сезнең утырышыгыз җитди укуга ишарә итсен-бу әдәп мәсьәләсенә кагыла.

9. Ятлаган аятьләрегезне туганнар, дуслар каршында укып күрсәтегез – булган кимчелекләр ачыкланыр, үз-узегезгә ышанычыгыз артыр, вакытыгызны сәваплы гамәл белән үткәрерсез.

10. Өйрәнгән сүрәләрегезне кабатлап торырга тырышыгыз, бигрәк тә намаз укыганда кулланыгыз.

11. Аллаһ Тәгалә белемнәрегезне дәвамлы, зиһенегезне зирәк кылсын өчен, гөнәһлардан сакланыгыз, гайбәтне калдырыгыз.

12. Мөмкин кадәр күбрәк Коръән уку түгәрәкләренә йөрегез. Җәмәгать намазларыннан соң да,бергәләп мәчеттә калып Коръән уку бик файдалы булыр.

13. Гыйлем өстәүче үзенең ашауна да игътибар итәргә тиеш:чамадан артык ашау зиһенне чуалта һәм шәһвәткә тарта.

14. Инде ниһаять беренче нәтиҗәләргә ирешкәннән соң, тәкәбберлек чиренә бирешә күрмәгез. Үзегез белән горурланмагыз. Хәдистә килә: “Кешене өч нәрсә һәләкатькә илтә: шуның берсе –үз-үзеңне артык ярату”?

15. Аллаһтан гыйлем сорап һәрдаим дога кылыгыз.

Коръәнне яттан белуче Мишари Рашиднең тәкъдим һәм нәсыйхатләре сезгә ярдәм итсен.

**Эльвира Хабибуллина әзерләде**.